**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.09.2016 Балык Бистәсе штп. № 152пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында

Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре һәм дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» 2016 елның 27 июнендәге 438 номерлы карарын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә карар бирәм:

1.2016 елның 1 июленнән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары «Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында»Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 7 мартындагы 34пи номерлы карары белән җайга салына торган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләренә 1280,0 сум күләмендә өстәмә түләү билгеләргә.

2. Өстәмә түләүнең бу чорда эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә ай саен түләнүен билгеләргә.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 20 декабрендәге 2291-р номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру» күрсәтмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 - 2018 елларда Татарстан Республикасында уртача фаразлана торган хезмәт хакының нисбәте динамикасын раслау турында» 2012 елның 20 декабрендәге 2291-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә гамәлгә ашырыла торган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренә, мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләре хезмәткәрләренең «Техник башкаручылар һәм ярдәмче состав артистлары вазыйфасы» һөнәри квалификация төркеменә караган хезмәткәрләреннән һәм эшче мәдәният, сәнгать һәм кинематография

һөнәрләре һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләреннән тыш, кагылмый дип билгеләргә.

4. Әлеге карар  2016 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча,  Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

Җитәкче Р.Х.Хәбибуллин